# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күлегәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Ожбуй торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**20 ноябрь 2020 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күлегәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Ожбуй торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 20 ноябрендә 10:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күлегәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Ожбуй пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Үлән чаптыру (хезмәт шартнамәсе буенча түләү);
2. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, юлларга хезмәт күрсәтү, кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май, запас частьләр сатып алу, хезмәт килешүе буенча түләү)
3. Ожбуй авылында Луговая урамы өчен вак таш сатып алу җәю

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 28 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 16 кеше, бу 57 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 16 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күлегәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Ожбуй торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күлегәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Ожбуй торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Үлән чаптыру (хезмәт шартнамәсе буенча түләү);
2. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, юлларга хезмәт күрсәтү, кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май, запас частьләр сатып алу, хезмәт килешүе буенча түләү)
3. Ожбуй авылында Луговая урамы өчен вак таш сатып алу һәм җәю

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Ю.Н. ВАСИЛЬЕВ